| | |
|---|---|
| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» ноябрь 2024 ел № 119

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2022 елның 27 июнендәге 57 номерлы “Мөлкәткә салым турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Норма авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2022 елның 27 июнендәге 57 номерлы “Мөлкәткә салым турында”гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктта «, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге Башлыгы Р.Н. Шарипҗанов